ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

______________ с. Верхний Услон ______________

Ана (гаилә) капиталы чараларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган индивидуаль торак төзелеше объектын төзү (реконструкцияләү) буенча төп эшләр башкаруны раслый торган документ бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

Югары Ослан муниципаль районы хакимияте органнарының физик һәм юридик затларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итү буенча эшчәнлеге нәтиҗәлелеген һәм сыйфатын күтәрү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 елның 2 декабрендәге 880 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен исәпкә алып, «Ана (гаилә) капиталы чараларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган индивидуаль торак төзелеше объектын төзү (реконструкцияләү) буенча төп эшләрне башкаруны раслый торган документны бирү кагыйдәләрен раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 18.08.2011 № 686 карары нигезендә, Югары Ослан муниципаль районы Уставы белән, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Ана (гаилә) капиталы чараларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган индивидуаль торак төзелеше объектын төзү (реконструкцияләү) буенча төп эшләр башкаруны раслый торган документ бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын расларга.
2. «Муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының «Индивидуаль торак төзелеше объектын төзү (реконструкцияләү) буенча төп эшләр башкаруны раслаучы документ бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2017елның 29 мартындагы 754 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
3. Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге начальнигына әлеге карар белән расланган муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын үтәүне тәэмин итәргә.
4. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында

урнаштырырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль-икътисади үсеш буенча урынбасарына йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе Л.С. Хакимзянов

Минһаҗев З.З.
2 нөсхәдә